ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Административ хокук бозулар турында**
**Татарстан Республикасы кодексының 8.2 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); 2015, № 3, № 4) үзгәреш кертеп, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8.2 статья. **Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар**

1. Региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген), дәүләт финанс контролен, шулай ук федераль дәүләт күзәтчелеге өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, $19.4^{1}$ статьясындагы 1 өлешендә, 19.5 статьясындагы 1 өлешендә, 19.7 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм белгечләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары җитәкчеләре һәм белгечләре, шулай ук вазыйфаи бурычларына эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген), дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыру керә торган башка вазыйфаи затлар төзи.

2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, $19.4^1$ статьясында, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.7 статьясында каралган хокук бозулар турында беркетмәләрне түбәндәгеләр төзи:

1) муниципаль районнарда, шәһәр округларында – муниципаль районнарның, шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре, аларның беренче урынбасарлары, урынбасарлары, муниципаль районнарның, шәһәр округларының башкарма комитетларындагы структур бүлекчәләр җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, шулай ук муниципаль районнардагы, шәһәр округларындагы башкарма комитетларның үз вазыйфаларына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру керә торган башка вазыйфаи затлары;

2) җирлекләрдә – җирлекләр башлыклары, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре, җирлекләрдәге башкарма комитетлар җитәкчеләренең урынбасарлары (секретарьлар), шулай ук җирлекләрдәге башкарма комитетларның үз вазыйфаларына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру керә торган башка вазыйфаи затлары.

3. Муниципаль берәмлекләрдә муниципаль финанс контролен гамәлгә ашырганда Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.21, 15.1, 15.11, 15.14 – $15.15^{16}$ статьяларында, 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, $19.4^1$ статьясында, 19.5 статьясындагы 20 өлешендә, 19.6 һәм 19.7 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнарының, башкарма комитетларның, финанс органнарының үз вазыйфаи бурычларына муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру керә торган вазыйфаи затлары төзи.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2015 елның 29 декабре
№ 110-ТРЗ